| РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН<br>ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ<br>БУИНСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>БУА<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |
|---|---|---|

| ПОСТАНОВЛЕНИЕ | | КАРАР |
|---|---|---|
| 03.03.2021 | Буа шәһәре | № 54/ИК-п |

Буа районы башкарма комитетының 2013 елның 09 сентябрендәге 404-п номерлы карары белән расланган, мәктәпкәчә белем бирү программасын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларына йөрүче балалары булган гражданнарга компенсация түләүләре бирү тәртибенә үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясы, «Дәүләт социаль ярдәме турында» 1999 елның 17 июлендәге 178-ФЗ номерлы Федераль закон, РФ Хөкүмәтенең «Социаль тәэмин итүнең Бердәм дәүләт мәгълүмат системасы турында» 2017 елның 14 февралендәге 181 номерлы карары нигезендә Буа муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Буа районы башкарма комитетының 2013 елның 09 сентябрендәге 404-п номерлы карары белән расланган, мәктәпкәчә белем бирү программасын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларына йөрүче балалары булган гражданнарга компенсация түләүләре бирү тәртибенә ( алга таба- Тәртип) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

- Тәртипнең 2 бүлеге 2.1 пунктын түбәндәге эчтәлекле 1 пунктча өстәргә:

"l) Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына түләүләр буенча бурыч барлыгы (булмау турында) белешмәләр.»;

- Тәртипнең 2 бүлеге 2.1 пунктын түбәндәге эчтәлекле 16нчы абзац өстәргә:

«Мөрәҗәгать иткән көнне Гариза бирүче Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына түләүләр буенча бурыч барлыгы (булмау турында) белешмәләр турында хәбәрдар булмаса (алга таба - түләүләр буенча бурыч), гариза бирүче белән турыдан-туры элемтәдә торучы хезмәткәр аңа гариза язу юлы белән, түләүләр буенча бурычлар булу яки булмавын ачыкларга тәкъдим итә (Кушымта). Гариза бирүченең түләүләр буенча бурычы булуы яисә гариза бирүченең гариза имзалаудан баш тартуы, гариза бирүче мөрәҗәгать иткән мәсьәләне караудан баш тарту өчен нигез була алмый.

Тәртипне «Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына түләүләр буенча бурычлар булу (булмау) турында мәгълүматлар бирү хакында» гариза белән тулыландырырга (карарга кушымта). »

2. Әлеге карар Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru/ адресы буенча рәсми басылып чыккан көннән законлы көченә керә, шулай ук Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре Порталында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://buinsk.tatarstan.ru адресы буенча урнаштырылырга тиеш.

3. Карарның үтәлешен тикшереп тотуны ТР Буа муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары Л. Н. Садретдиновага йөкләргә.

ТР Буа муниципаль районы Башкарма комитеты
җитәкчесе вазыйфаларын башкаручы Л.Р. Шакирҗанов

«Татарстан Республикасы Буа
муниципаль районы Башкарма
комитетының
« 03 » март 2021елның
54/ИК-п номерлы карарына
кушымта

Татарстан Республикасы Буа
муниципаль районы Башкарма комитеты
җитәкчесе вазыйфаларын вакытлыча
башкаручы______________________
_________________________________
*(Ф.И.А.и. /юридик зат исеме)*
__________________________________
*(паспорт мәгълүматлары / юридик зат турында белешмәләр)*
__________________________________
*(контактлы мәгълүматлар)*

Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына түләүләр буенча бурыч булу турында (булмау турында) белешмәләр бирү хакында
гариза

Минем *( ______________ юридик зат исеме)* Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына түләүләр буенча бурычларның булуы турында (булмавы турында) миңа белешмәләр бирүегезне сорыйм _____________________________________________________ .
(идентификацияләүче мәгълүматларны күрсәтергә: ИНН)

Гариза бирүче ________________________________ _________________________
(имза) (Ф.И.А.и. (булган очракта)

«Шәхси мәгълүматлар турында» 2006 елның 27 июлендәге 152-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә, әлеге гаризага язма рәвештә имза салынган көннән алып, язма рәвештә чакыртып алу көненә кадәр ризалык бирәм.
______________________________________________________________________________
(Ф.И.А.и. (булган очракта ), имза)